ТАТАРСТАН
ВЕТЕРАНЫ
№ 11
11 октябрь, 2022 ел
ВТ Безнең оешмага – 35 ел
РЕСПУБЛИКА ВЕТЕРАННАРЫ (ПЕНСИОНЕРЛАРЫ) ТӨБӘК ИҖТИМАГЫЙ ОЕШМАСЫ СОВЕТЫ ҺӘМ «ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН» ГАЗЕТАСЫНЫҢ УРТАК КУШЫМТАСЫ

СЕЗ – ҮРНӘК

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ РӨСТӘМ НУРГАЛИ УЛЫ МИҢНЕХАНОВ КОТЛАВЫ

Кадерле ветераннар!

Татарстан Республикасының танылган һәм абруйлы иҗтимагый оешмаларының берсен бәйрәм белән эчкерсез котлыйм!

Моннан 35 ел элек оештырылган Татарстан Республикасы ветераннары (пенсионерлары) төбәк иҗтимагый оешмасы бөтен республика күләмендә йөзләрчә мең өлкән буын вәкилен берләштереп, ветераннарны үз тирәсенә туплауга ирешә. Бүген сезнең оешма нык үсешле җирле бүлекләр челтәренә ия булып, иҗтимагый тормышта актив катнаша. Ветераннар һәм пенсионерларның социаль мәсьәләләрен хәл кылу буенча тырышлыгыгыз аерым ихтирам-хөрмәткә лаек. Аларның тормышын яхшырту өчен шартлар тудыру, актив озын гомер проектларына җәлеп итүнең дәүләт һәм җирле хакимият органнары белән берлектә алып барылуы сөендерә.

Оешманың тарихи кыйммәтләр һәм традицияләр нигезендә балалар, яшьләрне рухи-әхлакый, ватанпәрвәрлек рухында тәрбияләүне оештыруга керткән өлеше бәяләп бетергесез зур. Тарихи дөреслекне саклауда, Бөек Ватан сугышы каһарманнары исемнәрен мәңгеләштерүдә аеруча зур роль уйнавыгызны аерым билгеләп үтәргә кирәк.

Халык иҗатын һәм кәсепчелекне үстерү, әлеге бай мирасны киләчәк буыннарга тапшыру эше дә үзенең нәтиҗәләлегенраслый.

Хөрмәтле ветераннар! Тормышта актив позициядә торуыгыз – республикабызда яшәүчеләрнең барчасы өчен үрнәк. Татарстан Республикасы ветераннары (пенсионерлары) төбәк иҗтимагый оешмасына – алга таба да уңышлар, ә ветераннарның үзләренә нык сәламәтлек, иминлек һәм озын гомер телим!

ЗУР РӘХМӘТ!

Татарстан Республикасының Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәрип улы ШӘЙМИЕВ котлавы

Хөрмәтле ветераннар!

Хөрмәтле Хәбир Газизович!

Сезне республика ветераннарының абруйлы иҗтимагый оешмасы оештырылуга 35 ел тулу уңаеннан котлыйм!

Республикабызны торгызу һәм социаль-икътисади үстерүгә үзләреннән зур өлеш керткән ветераннарның барчасына рәхмәт сүзләре җиткерергә рөхсәт итегез! Әле бүген дә өлкәннәрнең тормышын яхшырту, яшь буында гражданлык җаваплылыгын тәрбияләү буенча зур эш алып баруыгыз күңелдә бик зур канәгатьлек хисләре тудыра.

Хәзерге вакытта үсеп килүче буында күпмилләтле халкыбызның рухи һәм әхлакый кыйммәтләренә нигезләнгән караш булдыру эшен көчәйтүне бик мөһим дип саныйм. Күпмилләтле Ватаныбызның көче һәм ныклыгы нигезе бу.

Без сезнең белән бергә яшь буынга ата-бабаларыбызның рухи һәм матди мирасын тапшыру эшчәнлеген арыймый-талмый алып барырга тиеш. Сезгә нык сәламәтлек, күңел көрлеге, тынычлык һәм иминлек телим!

КАЙБЫЧ «ӘЛМӘНДӘР»Е

Иске Чәчкаб авылында яшәүче Бөек Ватан сугышы ветераны Зиннәтулла Заһидуллин янына һәр баруымда аны Әлмәндәр бабайга охшатып кайтам.

Туфан Миңнуллинның Әлмәндәр карт образы аша яшәү мәгънәсенә ничек төшенсәк, Чәчкаб бабае белән аралашканнан соң да шундый хисләр кичерәсең. Аның да йөзе нур чәчә, елмаеп, иплән кенә сөйләшә, күпне күргән, мең дә берне белә, хәтере яхшы, юкка зарланып утыра торганнардан түгел, шаяртып та ала, тормышны ярата. Бу якты дөньяда бер гасырдан артык яшәүче Зиннәтулла бабайның язмышы халкыбызның үткәне, бүгенгесе белән тыгыз бәйләнгән. Узган ел 100 еллыгын билгеләп үткән ТАССРның чордашы ул.

Сугыш афәтләрен дә күргән, ике улын югалту хәсрәтен дә кичергән, биш бала табып үстергән хатыны Асия белән мәңгелеккә аерылышуына да 17 ел узып киткән. Хәзер ялгызы гына яши. Инде үзе дә җитмештән узган улы Шәүкәт Америкада төпләнеп калган, еш кайта алмый, билгеле. Кызы Алсу – Казанда, Илдусы Яшел Үзәндә гомер кичерә. Күршесендәге Фәридә ханым Абзалова аны үз әтиседәй карап-тәрбияләп тора, мунчасын да кертә.

– Кыш чыгарга улым Илдус гаиләсенә китсәм, җәйгә авылымны шулкадәр сагынып кайтам. Шәһәр халкы үзгәргән шул инде хәзер, подъезд төбенә чыгып утырам, никадәр кеше, яшьләр, балалар керә-чыга дигәндәй, ник берсе исәнләшсен, телефоннары колакларына береккән диярсең, – ди Зиннәтулла бабай. – Ә туган авылымда капка төбемнән узып китүче һәркем, ни хәл, Зиннәтулла абзый, дип кул биреп күрешә, хәлләремне сораша. Иии, рәхәт тормышта яшибез дә соң! Моннан йөз ел элек үлгән бабайны бу тормышка кире кайтару мөмкинлеге булса, аның бүгенге үзгәрешләрне күреп, мин җирдәге җәннәткә эләктем бугай, дип исләре китәр иде. Чыннан да, яшәү шундый матур бит!

«Син кая югалдың?»

– Мин, 101 нче яшь белән киткән бабай, бар күңелем белән Җиңү бәйрәмен көтәм. Фронтка кадәр үзебезнең авыл янында окоп казуда катнаштым. Бөек Ватан сугышы минем өчен Ржев шәһәреннән башланды. Курск дугасы, Белгород, Харьков шәһәрләрен азат итүдә катнаштым. Каты яралангач, Харьковтагы госпитальдә биш ай дәваландым, аннары Уфага җибәрделәр. Бәхетемә, Казаннан килгән хирург эләкте, – дип сөйли ул. – Аякларыңа энә белән төрткәч, бераз сизә башлады, димәк, аякка басачаксың, хәрәкәт кирәк, өмет зурдан, ди табиб. Ике шәфкать туташы, мине култыклап, һәркөнне икенче каттан өченче катка алып менә, алып төшә башлады. Бераздан, таякка таянып, әкренләп йөри башладым. 1944 елның 24 гыйнварында поезд белән Коләңгы станциясенә кадәр кайттым. Мине алты айга өйгә җибәргәннәр иде. Вакыты җиткәч, хәрби комиссариатка бардым, ләкин хирург Усанов тагын бер айсыз да юлга чыкмаска кушты. Яралар төзәлеп бетмәгән иде. «Үзебез чакырырбыз», – дип калган хәрби комиссар да мине тиз генә чакырмады. Сугыш та тәмамланды. «Син кая югалдың?» – дип мине үзенә чакыртып 15 минут сүккән хәрби комиссар икенче көнне гафу үтенде. Аңлавымча, минем документлар тутырылган папканы югалтып, аннары кабат таптканнар булып чыкты.

Ахыры 2 нче биттә ›

РЕСПУБЛИКАНЫҢ «АЛТЫН ФОНД»Ы!

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Фәрит МӨХӘММӘТШИН котлавы

Хөрмәтле ветераннар! Кадерле дуслар!

Быел Татарстан ветераннары (пенсионерлары) иҗтимагый оешмасы оештырылуга 35 ел тула. Дәүләт Советы депутатлары исеменнән һәм шәхсән үз исемемнән сезне республиканың иҗтимагый-сәяси тормышындагы әлеге мөһим вакыйга уңаеннан эчкерсез котлыйм!

Шушы еллар эчендә республика ветераннар советы, гомерләренең «алтын» һәм «көмеш» чорларына аяк баскан 980 меңнән артыграк активистны берләштереп, Татарстанның иң абруйлы иҗтимагый оешмаларыннан берсенә әйләнде. Сез республикабызның уңышлы килачәге өчен шәхсән җаваплылык хисен тоеп яшәүче, эш тәҗрибәсе һәм белеме белән уртаклашырга, хезмәттәшлеккә әзер булып торучы өлкән буын вәкилләрен бергә туплауга ирештегез. Оешма ветераннарының хокукларын һәм мәнфәгатьләрен яклау буенча системалы эш алып бара. Тормышта авыр хәлләрдә калган өлкәннәргә ярдәм кулы суза, аларның тормыш «көзе»нә җылылык өргәргә тырыша.

Без ветераннар хәрәкәте белән берлектә өлкән буынга социаль ярдәм һәм яшьләрне ватанпәрвәрлек рухында тәрбияләү мәсьәләләрен хәл итеп килә без. Уңайлы тормыш шартларын булдыруга, гомерне озайтуны күздә тоткан бик тә мөһим федераль һәм республика программаларын тормышка ашырабыз. Өлкәннәр, ветераннарның ихтыяҗлары һәм проблемаларына игътибарлы мөнәсәбәт республика хакимияте органнары эшендә өстенлекле юнәлеш булып калачак.

Ветераннар активы – республикабызның «алтын фонд»ы. Татарстан тәҗрибәгез, осталыгыгыздан, шулай ук сез тудырган матди һәм рухи кыйммәтләрдән башка гына шундый зур уңышларга ирешә алмас иде. Ветеран-пенсионерларның бүген дә үзләрен кирәкле итеп тоюлары, иҗтимагый эштә, волонтерлык һәм ихтыярилык эшчәнлегендә, иҗади проектларда (иң күренеклесе – «Балкыш» фестивале) актив катнашуы күңелдә канәгатьлек хисе тудыра.

«Балкыш» фестивале дистә ел эчендә кечкенә генә үзешчән чарадан җитди иҗади форумга, республиканың үзенчәлекле «визит карточкасы»на әйләнеп, илебезнең башка төбәкләрендә ветераннарның конкурс-смотрларын үстерүгә этәргеч бирде.

Бу эшне башлап йөрүчеләрнең берсе, Татарстан ветераннары (пенсионерлары) иҗтимагый оешмасы җитәкчесе Хәбир Газиз улы Иштирәковка туып-үскән Татарстаныбыз файдасына яңаны булдыру юлындагы уртак эшләр өчен аерым рәхмәт сүзләре җиткерәсем килә.

Хөрмәтле ветераннар! Зирәклегегез, сабырлыгыгыз, күпьеллык тырыш хезмәтегез өчен, яшь буынның тормышын рухи кыйммәтләрнең берниргә карамастан саклап калуына ышаныч белән сугаруыгыз, һәрвакыт безнең янәшәдә булуыгыз өчен рәхмәт!

Сезгә нык сәламәтлек, күңел күтәренкелеге һәм иминлек телим!

ТӨП БУРЫЧ – ӨЛКӘННӘР ХАКЫНА ЭШЛӘҮ

Татарстан Республикасы ветераннары (пенсионерлары) төбәк иҗтимагый оешмасы рәисе Хәбир ИШТИРӘКОВ котлавы

Кадерле дуслар – ветераннар эше буенча коллегалар!

Безнең оешма 1987 елның 21 мартында ТАССР сугыш һәм хезмәт ветераннарының гамәлгә кую конференциясендә оештырылып, данлыклы, вакыйгаларга бай юл узды. Бүген ул – республикадагы иң абруйлы һәм иң ишле иҗтимагый берләшмәләрнең берсе. Республика пенсионерларын – ветераннарны берләштерүче оешма нигезе салынуының беренче көннәреннән үк Татарстан иҗтимагый тормышында: өлкәннәрнең социаль-икътисади хәлен яхшыртуда, яшьләрне ватанпәрвәрлек рухында тәрбияләү, социаль юнәлеше республика законнарын эшләүдә турыдан-туры катнашты. Болар – 1991 елда республикада кабул ителгән тиндәшсез «Забота» программасы, «Ничек яшисең, ветеран?» рейды, «Ветеранның йорт хуҗалыгы» комплекслы программасы, «Татарстанда яшәүчеләргә адреслы социаль ярдәм программасы» һәм өлкәннәр өчен мөһим башка программалар. 1992–1995 елларда Татарстанда Ветераннар советы катнашында өлкәннәргә социаль ярдәм итү буенча барлыгы 26 закон һәм карар кабул ителде.

Республиканың ветераннар активы инде күптәннән дәүләт идарәсе органнары белән өлкәннәр арасындагы күпер ролен үти. Узган шушы 35 ел эчендә без, эш алымнары һәм формаларын камиллаштереп, алга баруыбызны күрсәттек. Бүген безнең 55 җирле һәм 3 меңгә якын башлангыч ветеран оешмасы, 45 меңнән артыграк активист бар. Алар – сугыш кырларында һәм тылда җиңү өчен мөмкин булганның барын да эшләгән, илне хәрабәләрдән торгызган, ватаныбызның иң зур төзелешләрендә хезмәт куйган, һәрвакыт алгы сызыкта булган, зур ихтирам-хөрмәт казанган кешеләр.

Архив фотосурәтләрен барлаганда, оешмабызның эшчәнлеге колачына хәйран каласың: шушы 35 ел эчендә күпме чаралар оештырылган, үткәрелгән, күпме нәрсә гамәлгә кертелгән, күпме юллар үтелгән! Аксакалларыбызның илһам көченә, яшьлегенә сокланып туя алмыйм. Өлкәннәребез җәмәгать башлангычында шуның кадәр күп хезмәт куя! Аларның һәммәсе дә – үз эшләре өчен чын мәгънәсендә янып йөрүчеләр, ватанпәрвәрләр. Вакытлар үзгәрә, без дә үзгәрәбез. Ләкин өлкән буынны кайгырту һәм ватанпәрвәрлек эше генә үзгәрешсез кала. Төп ике бурычыбыз бу. Аларның һәркайсы буенча байтак эшләр башкарылды. «2025 елга кадәр Россия Федерациясендә өлкәннәр мәнфәгатьләрендәге гамәлләре стратегиясе» нигезләмәләре өлкән яшьтәгеләрнең тормыш эшчәнлегенең барлык якларын колачлый. Нәтиҗәдә өлкән буын вәкилләренең саны тайпылышсыз арта, җәмгыятьтә тоткан урыны үсә. Соңгы вакытларда бу юнәлештәге файдалы башлангычлар бихисап. Болар – оешманың «Бөек Ватан сугышының гаилә фотохроникасы» Бөтенроссия проектындагы җиңүләре дә, республикада «көмеш» волонтерлар хәрәкәтен, өлкәннәрнең иҗади һәм физик мөмкинлекләрен үстерү, өлкән яшьтәгеләрнең тормышын яхшыртуга юнәлдерелгән социаль проектлар өчен грантлар һәм, әлбәттә инде, оешмабызның брендына әйләнгән «Балкыш» фестивале дә. Ялгыз һәм аз керемле пенсионерлар, сугышта катнашучылар, һәлак булган хәрбиләрнең хатыннары – аерым игътибар үзәгендә. Ветераннар советлары активистлары урыннарда һәркемгә игътибар итәргә, эшен беркем дә онытылып калмаслык итеп оештырырга тырыша. Алар чын күңелдән яшь буынның киләчәген кайгырта, оныкларыбызда һәм оныклар балаларында республикабызның үткәне, бүгенгесенә карата кызыксыну тудырырга, ата-бабаларыбызның данлыклы җиңүләре белән горурланырга өйрәтә.

Барлык хакимият органнары, социаль партнерларыбыз белән өлкәннәр хакына тыгыз элемтәдә эшләү – безнең төп бурыч әнә шул. Халыкның якынча өчтән бер өлеше – гаять зур көч бу. Өлкән буынның әлегә файдаланылмаган мөмкинлекләре барлык юнәлешләрдә чиктән тыш зур. Шуңа күрә ирешелгәннәр белән тынычланып калырга иртәрәк. Алда кызыклы, файдалы бик күп эшләр тора.

Кадерле коллегалар! Күп еллар дәвамындагы нәтиҗәле хезмәттәшлек, иксез-чиксез илһам көче, күңел җылысы, эшегезгә фидакарьләрчә тугрылыгыз өчен рәхмәт! Тәҗрибәгез, изге эшләрегез, туып-үскән Татарстаныбызны үстерүгә керткән зур өлешегез өчен рәхмәт! Сезгә чын күңелдән нык сәламәтлек, озын гомер, кызыклы яңа проектлар һәм иҗат көче телим!

Кайбыч «Әлмәндәр»е

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Хирург Усанов сугышка китүне бер айга кичектермәгән булса, минем алдагы язмышым ничек булган булыр иде, белмим.

Эшләп узды гомерем

Гомере тырыш хезмәттә узган Зиннәтулла Заһидуллинның. Район финанс бүлегендә эшләгәндә, Иске Чәчкаб авылыннан Олы Кайбычка кадәр һәр көнне алты чакрым араны җәяү йөргән. Район таркалгач, утыз елдан артык дәүләт салымнары буенча өлкән инспектор булган. Эштәге уңышлары һәм социалистик йөкләмәләрне үтәгән өчен ТАССР Финанслар министрлыгы һәм Дәүләт учреждениеләре профсоюзы хезмәткәрләренең Мактау кәгазенә лаек булган. Апаста да финанс бүлегендә эшләгән.

«Тәмәкене дә, башкасын да инде күптән ташладым»

Озын гомерле булуын гел хәрәкәттә булуында, сәламәт яшәү рәвеше алып баруында күрә ул.

– Без яшь чакларда транспорт юк иде бит, авыллар арасын тәпи-тәпи атларга туры килде. Алты чакрым ераклыктагы Олы Кайбыч мәктәбенә дә җәяү йөреп укыдым. Җәяү йөрүнең файдасы күп, диләр, ул чакта без аны уйламаган да инде, – ди ул. – 1960 елга кадәр көнөнә икешәр кап тәмәке тарта идем. Хәмере дә эчелгәндер инде. 1967 елда бик каты грипп белән авырдым, сулыш алу да кыенлашты. Шулвакыт тәмәкене дә, башкасын да бөтенләйгә ташладым. Дин юлыннан киттем, намазга бастым, пенсиягә чыккач, авылда имам да булып тордым. Озын гомерле булу дерес тукланудан да килә.

100 яшьлек аксакал начар гадәтләрне үз итмәскә, сәламәтлекнең кадерен белеп яшәргә чакыра. Теләге дә тормышка ашсын: Җиңү тантанасына күп калмады бит.

Луиза СӨНГАТУЛЛИНА

Татьяна ЛАРИОНОВА, Россия Дәүләт Думасы депутаты:

– Татарстан ветераннар советына – 35 ел! Миңа беренче җитәкче, көчле лидер, ветераннар хәрәкәтен оештыручы Тимашова Надежда Ивановнаны якыннан белү бәхете тиде. Ул елларда Татарстанның ветераннар советы илебезне танытты. Ветераннарның иҗтимагый оешмасы өлкәннәргә ярдәм итү өчен министрлыклар, ведомстволар, предприятиеләр һәм оешмалар белән элемтәдә торды. Республикада «Забота» программасы барлыкка килде. Пенсияләрнең вакытында түләнүе, даруханәләрдә дарулар булу, азык-төлек кибетләрендәге бәяләрне контрольдә тоту кебек сораулар халыкны борчыды да инде! Шул чорда ветераннар советының активлыгы, үҗәтлеге аркасында күпме мәсьәлә хәл ителде.

Бүген ветераннар советлары зур күләмле социаль әһәмияткә ия проектлар уйлап таба, аны яклый һәм тормышка ашыра, патриотизм, милләтара һәм конфессияара татулык традицияләрен формалаштыра, гаилә кыйммәтләрен саклауга үрнәк булып тора.

Рәхмәт сезгә! Хөрмәтле ветераннар, сезгә сәламәтлек, җан тынычлыгы, иминлек телисем килә. Тормышыгызның һәр яңа көне өмет, кызыклы иҗади идеяләр, күңелле очрашулар белән тулып торсын. Һәрберегезгә күңел тынычлыгы, хәзерге көнгә ышаныч, тормышыгызның алдагы елларына өмет телим! Бәйрәм белән сезне!

Владимир ЕПИФАНОВ, Бөтенроссия сугыш, хезмәт, Кораллы Көчләр һәм хокук саклау оешмаларының ветераннар (пенсионерлар) иҗтимагый оешмасы рәисе:

– Бөтенроссия ветераннар оешмасы һәм шәхсән үз исемемнән республиканың барлык ветераннарын чын күңелдән сәламлим һәм оешмагызга 35 ел тулу белән тәбрик итәм! Россия ветераннар хәрәкәте сафларында 970 меңнән артык ветеранны берләштергән Татарстан ветераннары (пенсионерлары) төбәк иҗтимагый оешмасы – хәрби, хезмәт һәм тормыш тәҗрибәсе, бай традицияләре булган иң эре оешмаларның берсе.

Узган елларда сезнең оешма республиканың яшь буынын патриотик тәрбияләү һәм җәмгыятьне берләштерү эшенә саллы өлеш кертүче, төбәк пенсионерлары һәм ветераннарының законлы хокукларын һәм мәнфәгатьләрен яклаучы иҗтимагый оешмага әверелде. Оешма тарафыннан үткәрелә торган һәр эш ветераннарның тормыш сыйфатын күтәрүгә, өлкән яшьтәге кешеләргә карата хөрмәт белән карауга, төбәктә уңайлы социаль хәл булдыруга юнәлтелгән.

Оешманың нәтиҗәле эшендә, ветераннарга кагылышлы барлык мәсьәләләр буенча республика хакимият органнары белән эш итә белүендә ветеран активы, оешма рәисе Иштирәков Хәбир Газиз улына зур рәхмәт!

Хөрмәтле дуслар!

Хезмәтегез, зирәклегегез һәм тәҗрибәгез, игелекле гамәлләрегез, ветераннар хәрәкәтен үстерүгә керткән зур өлешегез өчен тирән рәхмәтебезне кабул итегез! Актив тормыш позициясе, гаять зур ихтыяр көче, өлкән буын кешеләренә хас бетмәс-төкәнмәс энергиягез яшьләр өчен үрнәк булып тора. Барлык ветераннарга нык сәламәтлек, иминлек, тормыш көчләре һәм күңел җылысы, мөмкин кадәр күбрәк уңай хис-кичерешләр телим!

Оешмага алга таба да тотрыклы үсеш, ветераннар бәхете өчен уңышлы эшчәнлек телибез! Бәйрәм белән сезне!

МИН ХӘТЕРЛИМ ӘЛЕ!

Ветераннар илнең үткәнен, бүгенгесен һәм киләчәген бәйләүче алтын чылбыр булып тора. Өлкәннәр илебез һәм республикабызга бәйле күп кенә хатирәләрне саклыйлар. Сезгә, хөрмәтле ветераннар, гаделлек, тугрылык, балалар турында кайгырту, яшьләргә хөрмәт белән карау кебек әхлакый кыйммәтләр хас.

Менә 35 ел инде Татарстан Республикасы ветераннарының (пенсионерларының) төбәк иҗтимагый оешмасы өлкән буынның хокукларын һәм мәнфәгатьләрен яклый. Оешма бер максат белән эшли. Ул ветераннар хәрәкәтенең активлыгын күтәрүгә, пенсионерларның хокукларын һәм мәнфәгатьләрен яклауга, өлкән буынның җәмгыятьтә лаеклы урынын саклап калуга хезмәт итә.

Татарстан Республикасы ветераннарының (пенсионерларының) төбәк иҗтимагый оешмасының төп бурычларының берсе – яшьләрдә ватанпәрвәрлек тәрбияләү. Буыннарның бу элемтәсе әхлакны, яшьләребезнең сәламәтлеген тәрбияләүдә бик кирәк дип саныйм. Яшь буынга тәрбия бирүдә ветераннарның катнашуы бик кирәк. Чөнки нәкъ менә ветераннар белән турыдан-туры аралашу яшь буынга үз Ватанының тарихын белергә, өлкән буынга хөрмәт күрсәтергә өйрәнергә, дөрес карарлар кабул итәргә мөмкинлек бирә.

Оешма үзен бар яктан үрнәк итеп күрсәтә. Өлкәннәр бик актив. Алар бик күп проектларны тормышка ашырырга булыша. «Балкыш – Сияние» үзешчән коллективлар фестивален генә алыйк. «Ярдәм» проекты, «Гаилә фотохроникалары» республика конкурсы, «Ветеранга – ветераннар игътибары» акциясе – боларның барысында да өлкәннәр актив катнаша.

Татарстанда ветераннар хәрәкәтенең ничек башлануын мин бик яхшы хәтерлим. Ул чакта Яшел Үзән районы башлыгының социаль мәсьәләләр буенча урынбасары булып эшли идем. Иң беренче булып Яшел Үзәндә ветераннар советын Тимур Нигъмәтуллин җитәкләде. Бербер артлы эре заводларда беренчел оешмалар барлыкка килә башлады. Надежда Ивановна Тимашованың районга килүе исемдә калган. Аның зирәклеге һәм гаделлеге, шат күңеллелеге һәм ягымлылыгы, ихласлыгы һәм яхшылыгы аңа һәрвакыт төрле буын кешеләре белән тату яшәргә һәм үз тирәсенә фикердәшләрен тупларга ярдәм итә иде.

Татарстан Республикасы ветераннары (пенсионерлары) иҗтимагый төбәк оешмасын бәйрәм белән чын күңелдән котлыйм.

Хезмәтегез өчен чын күңелдән рәхмәт белдерәсем килә. Эшегездә уңышлар, нык сәламәтлек, бәхет һәм иминлек телим!

Сәрия САБУРСКАЯ,
Татарстанның Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкиле

Илдус МОСТЮКОВ, Социалистик Хезмәт Герое:

– 1990 елда сәламәтлегем аркасында эштән туктарга туры килде. Бервакыт хастаханәдә ятканда, Республика ветераннар оешмасы рәисе урынбасары Әгъләм Камалов белән бер палатага туры килдек. Танышып киттек. Ул фәнни-тикшеренү үзәгендә эшләгәнемне һәм инде хәзер анннан киткәнемне белгәч, үзләренә чакырды. «Өйдә нишләмәкче буласың, әйдә безгә», – диде. Бераз уйлагач, ризалаштым. Әгъләм Камалов мине ул чакта ветераннар советы рәисе вазыйфасында эшләгән Надежда Тимашова янына алып керде. Бераз сөйләшкәч, Тимашова оешмада социаль мәсьәләләр комиссиясен җитәкләргә тәкъдим итте. Каршы килмәдем.

Эш җиңел булмады. Халыкның сораулары күп җыелган иде. Шуңа да эшне аларны кабул итүдән башладык. Ветераннар үзләрен ничек яклыйсын да белми иде хәтта. Көн саен унар кешене кабул иттек. Күбесе эч серләрен булса да сөйләп китә иде. Без дә өлкәннәргә ничек тә ярдәм итәргә тырыштык. Җитәкчеләр белән даими элемтәдә тордык. Мөрәҗәгатьләрне министрларга җиткердек.

Бервакыт безнең оешмага Татарстанның Беренче Президенты Минтимер Шәймиев килде. Мине Татарстанда яшәүче Геройларның хәле борчый иде. Ул вакытта бездә 111 Советлар Союзы һәм Социалистик Хезмәт Герое исәпләнде. Әмма алар үзләренә тиешле ташламадан да файдалана алмыйлар, вакытында пенсияләре дә бирелми. Минтимер Шәймиевкә шул үтенечемне язып тапшырдым. Ул аны укыды да кесәсенә салды. Бераз вакыт узды. Мине онытканнардыр инде дисәм, Президентның кабул итү бүлмәсеннән шалтыратып, очрашуга чакырдылар. Хәтта мине алырга машина да җибәрделәр. Очрашкач, Татарстанда яшәүче Геройларның хәле турында сөйләштек. «Үзең нәрсә тәкъдим итәсең?» – ди Президент. «Татарстанда Геройларның иҗтимагый оешмасын төзик әле», – дим. Каршы килмәде. Шулай итеп, мин әлеге оешманың рәисе булдым. Республика ветераннар (пенсионерлар) төбәк иҗтимагый оешмасыннан китәргә туры килсә дә, озак вакыт президиум әгъзасы булып тордым. Аларны чын күңелдән бәйрәмнәре белән тәбрик итәм!

Вәгыйз МАЛИХОВ:

– Мин ветераннар эшчәнлегенә 32 ел гомеремне бирдем. Шуның 21 елын Татарстанның ветераннар оешмасы рәисе урынбасары булып эшләдем. Пенсиягә чыктым да яңадан эшкә урнаштым. Бер генә көн дә ял итмәдем. 92 яшемә кадәр эшләдем. Хезмәт стажым – 79 ел. Бер дә үкенмим. Сәламәтлек барда ничек эшләми ятасың?! Гел кешеләр белән эшләргә туры килде. Ә бит яшьлегем дә җаваплы эшләрдә узды.

Актаныш районында туып-үскән егет мин. Җиде класс белемем бар иде. Җитәкчеләр эшләгәнемне күреп алды. Минзәлә районында партия райкомының икенче секретаре булып эшләдем. Шуннан мине Аксубайга күчерделәр. Анда башкарма комитет рәисе булып эшләдем. Ул чакларда без беренчеләрдән булып республикадагы бараклардан котылдык. Команда белән эшли белүем, эшемә җаваплы каравымны күреп, Баулыга җибәрделәр. Аннан Ютазы районында эшләдем. Актаныш районы газетасының баш мөхәррире булып та эшләргә туры килде.

1987 елның 21 мартында республика ветераннар (пенсионерлар) советы иҗтимагый оешмасының конференциясе узды. Мин анда катнашучылар арасында идем. Ул вакытта Түбән Кама һәм Чаллы шәһәрләрендә ветераннар оешмасы эшли иде инде. Алар 1985 елда ачылды. Ветераннар оешмасына 1991 елда чакырып китерделәр. Анда ветераннар һәм тыл хезмәтчәннәрен социаль яклау комиссиясен җитәкли башладым. Ул вакытта республикада Бөек Ватан сугышында катнашучы 94 мең кеше исәпләнә иде. Ул елларда эшләү җиңел булмады. Кибетләрдә товарлар юк, йортлар салынмый, транспортта йөрү өчен ташламалар бирелми. Без ул чактагы ветераннар советы рәисе Надежда Тимашова белән көн саен өлкәннәрне кабул иттек. Меңләгән зар ишетә идек.

Әкренләп районнарда ветераннар советларын ача башладык. Авылларда исә кешеләрнең проблемасы бөтенләй башка. Аларның малына ризык, бакчасын сөреп бирү, өенә ремонт, ягулык кирәк. Шунлыктан без республика күләмендә «Забота» ярдәм чарасын башлап җибәрдек. Татарстан районнары буйлап йөреп чыктык. 800 фронтовик йортында булдык. Безне ишетә башладылар. Кибетләрдә сугыш ветераннары өчен ташламалы бүлекләр ачылды, өлкәннәр мунчада ташлама белән юына. «Көнкүреш йортлары»нда ветераннарның өс киемнәрен төзекләндереп бирәләр. Өлкәннәр транспортта бушлай йөри, коммуналь хезмәтләр өчен түләгәндә ташламадан файдалана. Әнә шундый мөмкинлекләр пәйда булды.

Хәзер инде бөтенләй башкача. Республикада ветераннар һәм пенсионерларның тормышлары күпләр кызыгырлык. Алар бии дә, җырлый да, мәдәниятебезне, гореф-гадәтләребезне яшь буынга тапшыралар. Татарстанның ветераннар (пенсионерлар) советының төбәк иҗтимагый оешмасын җитәкләүче Хәбир Ииштирәков – үз эшенең остасы. Кайчандыр, бу егет булдырачак, дигән идем. Ә ул өметләрне аклап кына калмады, күпме өлкән кешене яшьләргә кайтарды. Үзегез күреп торасыз: хәзер өлкәннәр картаюны белми. Үземнең дә йөрәк 18дә әле! Озак яшәүнең сере юк аның – гел хәрәкәттә, кешеләр арасында, кемгәдер файда китереп яшәргә генә кирәк!

ЯШӘҮ БЕЛӘН ҮЛЕМ АРАСЫНДА 900 КӨН

Кукмара районының Өлге авылында Ленинград блокадасын кичергән Хәтирә Салихова яши. Ветеранның язмышы туган авылы Өлге белән бәйле. Ул биредә туа, моннан фронтка китә һәм шунда ук әйләнеп кайта.

Сугыш башланганда Хәтирәгә18 яшь була. Фронтка башта ир-атларны, егетләрне алып китәләр, аннан чират хатын-кызларга җитә. Кызның кулына повесткаа колхозда эшләгән вакытта тоттыралар. 1942 елда Хәтирәне Арча хәрби комиссариатыннан Мәскәү өлкәсенә җибәрәләр. Химки шәһәрендә ул радист белгечлеге ала, аннары эшелонга утыртып, Ленинград фронтына озаталар.

– Эшелоннан төшергәннән соң, безгә ак кием бирделәр. Нева елгасындагы шәһәргә кадәр Ладога өстендәге боздан 60 чакрым тирәсе җәяүләп бардык. Өстә фашист очкычлары оча, бомбалар ява, кар көртләре артына качабыз да алга таба шуышабыз. Без Киров исемендәге хәрби заводны саклаучы аэростат частенда хезмәт иттек. Дошман самолетларын күргәч, аэростатларны газ белән тутырып, һавага җибәрдек. Аларны металл арканнар ярдәмендә тарттырырга һәм өскә үрләргә кирәк иде. Ул вакытта куллар канга батып, тән тиресе сыдырылып бетте, – дип искә ала ул. – Тик андый чакта бу турыда уйлыйсыңмы соң?! Әле дә хәтерлим: бервакыт төнлә каравылда торганда күктә балкып янучы йолдызларны, айны күзәтәм. «Эх, бу айны әнием күрәме икән?» – дип уйлыйм. Күздән яшь ага.

Алар хатын-кызлар частенда Татарстаннан барлыгы 24 кыз хезмәт итә. Командирлар һәрвакыт: «Татар кызларыннан үрнәк алыгыз», – дип тора.

– Без килеп, ике көн узгач, шәһәр тирәли фашист блокадасының боҗрасы ябылды. Ачлык башланды, кешеләр сөякә калды. Җирле халык белән чагыштырганда, без хәллерәк, тазарак күренә идек. Тәүлеклек икмәк нормасы – 125 грамм. Көн буена пычкы чүбеннән, түптән пешерелгән бер кисәк икмәк һәм сыек шулпа бирделәр, анда бары тик өч арпа ярмасы гына йөзеп йөрер иде. Ашарга бернәрсә юк, хәтта урамда яшеллек тә, кошлар да калмады: бөтенесен тотып ашап бетерделәр. Блокада 900 көн диярлек дәвам итте, бары тик 1944 елның 27 гыйнварында гына ул тулысынча азат ителде, – дип сөйли Хәтирә апа. – Җиңү турындагы озак көтелгән хәбәрне дә Ленинградта ишеттек без. Төнге сәгать икедә уятып, каты тавыш белән торырга кушып әмер бирделәр, ә аннары сугыш беткәнен әйттеләр, тик шәһәрдә чыкмаска куштылар. Шул чакта рәхәтләнеп җырладык, биедек, кочаклашып елаштык.

Хәтирә апа, үзенең горурлыгы – озын толымын кисеп, посылка белән әнисенә җибәргәнен дә бик яхшы хәтерли. Ул чакта сугышта аларны тәрбияләү өчен тиешле шартлар булмый. Шуңа чәчләрен кистерергә туры килә дә инде.

Ленинградта кызлар часте 1945 елның августына кадәр тора. Алар шәһәрне җимерекләрдән чистартырга ярдәм итә. Аннан вагоннарга төяләп, өйләренә юл алалар. Ул үзе белән 10 килограмм он һәм консервлар алып кайта. Хәтирә апаны туган авылында әнисе Сәрбиназ каршы ала. Кызының исәнлеге өчен әнисе Коръән укытып, аш үткәрә.

Сугыштан соң Хәтирә апа Кукмара вокзалы янындагы почтада 35 елга якын хезмәт куя. Калинин фронтында танк пулеметчигы булып сугышкан фронтовик Мөбарәкҗан Салихов белән 1954 елда гаилә коралар. Алар ике кыз – Әлфия белән Асияне тәрбияләп үстерәләр. Бүген ике онык һәм биш оныкчыкларына сөенеп гомер кичерәләр.

Алсу ГАТАУЛЛИНА

ТАТАРСТАН ВЕТЕРАНЫ
Республика ветераннары (пенсионерлары) төбәк иҗтимагый оешмасы советы һәм «Ватаным Татарстан» газетасының уртак кушымтасы.
Чыгарылыш өчен җаваплы – **Гөлгенә ШИҺАПОВА**. Биткә салучы һәм бизәүче – **Рөстәм МИҢНУЛЛИН.**
Безнең адрес: Казан шәһәре, Театр урамы, 5 й.
Телефон: 8(843) 238-16-88
Электрон адрес: soovp.kzn@tatar.ru